МИНИСТЕРСТВО
ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_____________ №_____________

г.Казань

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итү Тәртибе турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273 номерлы номерлы Федераль законның 9 статьясы 5 өлеше нигезендә боерык бирәм:

1. Расларга:
   1.1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итү Тәртибен (Боерыкка 1 номерлы кушымта);
   1.2. Дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итү тәртибендәге белешмәләр исемлеген (Боерыкка 2 номерлы кушымта).
2. Структур бүлекчәләр җитәкчеләренә әлеге Боерыкны хезмәткәрләр игътибарына җиткерергә.
3. Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2009 елның 8 июнендәге “Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы хезмәткәрләренең коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрдар итү Тәртибе турында” 179 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министр урынбасары - министр А.Ә.Кәримов

Татарстан Республикасы
сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының
_____ елның __________
______ номерлы боерыгына
1 номерлы Кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итү
Тәртибе

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итү Тәртибе (алга таба – Тәртип) 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273 номерлы номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында (алга таба - дәүләт хезмәткәрләре, Министрлык) коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итү процедурасын регламентлый, шулай ук хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе һәм андагы белешмәләрне тикшерүне оештыру.

2. Дәүләт хезмәткәре кичекмәстән аңа карата булган коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактларының һәрбер очрагы турында Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры (алга таба-министр) йөзендә эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итәргә бурычлы.

Дәүләт хезмәткәре командировкада булган очракта, ялда, хезмәт урыныннан еракта булган вакытларда ул хезмәт урынына кайту белән кичекмәстән бу хакта министрны хәбәрдар итәргә мәҗбүр.

3. Дәүләт хезмәткәре әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән үзенең хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәмәгәндә хокук бозу очрагы буларак Россия Федерациясе законы нигезендә дәүләт гражданлык хезмәтеннән азат ителә яисә башка төр җаваплылыкка тартыла.

4. Дәүләт хезмәткәре, Министрлыкта Татарстан Республикасы башка дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт вазыйфаларны башкарган вакытта коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында билгеле булган очракта әлеге Тәртиптә билгеләнгән процедураны саклап бу хакта министра хәбәр итәргә хокуклы.

5. Коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итү (алга таба – хәбәрдар итү) язмача рәвештә әлеге Тәртипнең 1 номерлы кушымтасындагы формага нигезләнеп башкарыла һәм коррупция һәм башка хокук бозуларга

каршы профилактика эше өчен җаваплы булган вазыйфаи затка тапшырыла, яисә почта аша җибәрелә.

6. Хәбәрнамәгә коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактларын раслаучы барлык булган материаллар да өстәлә һәм мөрәҗәгатькә бәйле булган башка төр документлар да теркәлә.

7. Хәбәрнамәләрне теркәү коррупция һәм башка хокук бозуларга каршы профилактика эше өчен җаваплы булган вазыйфаи зат тарафыннан башкарыла.

8. Хәбәрнамәләрне теркәү эшкә алучы (эш бирүче) вәкилнең Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрдар итү “Хәбәрнамәләрне теркәү журналы”нда (алга таба – Журнал) әлеге Тәртипнең 2 номерлы кушымтасындагы формага нигезләнеп теркәлергә мәҗбүр.

Журнал битләре тегелә, номер сугыла һәм Министрлык мөһере сугыла.

9. Теркәү хәбәрнамәне кабул итү вакытында башкарыла.

10. Хәбәрнамәне теркәүдән баш тарту мөмкин түгел.

11. Журналда теркәлгән хәбәрнамә шул ук көнне министр карамагына тапшырыла, яисә анда күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерүне оештыру өчен аны алыштыручы җаваплы затка бирелә.

12. Хәбәрнамәдә күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерүне оештыру эшен министр кушуы буенча моңа вәкаләтле зат башкара.

13. Тикшерү хәбәрнамә теркәлгән көннән алып өч эш көне эчендә уздырыла.

14. Тикшерү барышында хәбәрнамәдә күрсәтелгән мәгълүматларда хокук бозу билгеләре булу билгеләнә.

Тикшерү барышында зарур булган очракта хәбәрнамәдә күрсәтелгән мәгълүматлар буенча дәүләт хезмәткәрләре белән сөйләшүләр үткәрелә.

15. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү материаллары теркәлгән хәбәрнамә министрга тапшырыла, аның карары буенча материаллар теркәлгән хәбәрнамә прокуратура органнарына, эчке эшләр яисә башка органнарга юнәлтелә.

16. Прокуратура органнарына, эчке эшләр яисә башка органнарга хәбәрнамә журналда теркәлгәннән соң 7 көн эчендә юнәлтелә, бу хакта коррупция һәм башка хокук бозуларга каршы профилактика эше өчен җаваплы булган вазыйфаи зат хәбәрнамәне биргән яисә җибәргән дәүләт хезмәткәрен хәбәрдар итә.

Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
Татарстан Республикасы сәнәгать һәм
сәүдә министрлыгында коррупцияле
хокук бозуга этәрү максатыннан
мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә
алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итү
Тәртибенә 1 номерлы Кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрына

________________________________________

________________________________________
(Ф.И.Ә.,вазыйфасы)

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итү

1. Коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итәм (алга таба – хокук бозуга этәрү)

____________________________________________________________
(Ф.И.Ә. күрсәтелә, вазыйфа, хокук бозыга этәргән физик (юридик) зат турында билгеле булган мәгълүмат)

____________________________________________________________

2. Хокук бозуга этәрү минем тарафтан башкару максаты беләнn______________________________________________________

____________________________________________________________
(хокук бозуга этәрү эчтәлеге күрсәтелә)

3. Хокук бозуга этәрү түбәндәге чара ярдәмендә башкарылды

________________________________________________________
(этәрү ысулы: сатып, куркыту, ялган һәм башкалар)

4. Хокук бозуга этәрү вакыты ______сәг. _______мин.,
«____»__________20___ел. _______________________________________
(шәһәр, адрес)

5. Хокук бозуга этәрүне ашыру

____________________________________________________________
(этәргән шартлар: телефоннан сөйләшү, шәхси очрашу, почта һәм башкалар)

"__" ___________ 20__ ел. ____________________________ __________
(хәбәрнамә юллаучының имзасы,(имзаның тулы язылышы)

Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
Татарстан Республикасы сәнәгать һәм
сәүдә министрлыгында коррупцияле
хокук бозуга этәрү максатыннан
мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә
алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итү
Тәртибенә 2 номерлы Кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан
мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар итүне теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Хәбәрнамә теркелгән дата | Хәбәрнамә теркәлгән номер | Ф.И.Ә., хәбәрнамәне биргән затның вазыйфасы | Хәбәрнамәне биргән затның имзасы | Хәбәрнамәне кабул иткән затның Ф.И.Ә. | Хәбәрнамәне кабул иткән затның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы
сәнәгать һәм сәүдә
министрлыгының
_____ елның __________
______ номерлы боерыгына
2 номерлы Кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең
Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында
коррупцияле хокук бозуга этәрү максатыннан
мөрәҗәгать итү фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкилне хәбәрдар
итүдә булган мәгълүматлар
ИСЕМЛЕГЕ

1. Хәбәрнамәне юллаган дәүләт гражданлык хезмәткәренең Фамилиясе, Исеме, Әтисенең исеме, аның вазыйфасы, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының структур бүлекчәсе.
2. Хокук бозуга этәрүче физик (юридик) зат турында билгеле булган барлык мәгълүмат, (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазыйфасы һәм башкалар).
3. Булырга мөмкин булган хокук бозуның асылы (вазыйфаи вәкаләтләреннән файдалану, бюджет чараларын максатсыз туздыру, вазыйфаи вәкаләтләрен арттыру, җитәкче вазыйфаи зат вәкаләтләрен үзенә алу, эшмәкәрлек эшчәнлегендә законсыз катнашу, ришвәт алу, ришвәт бирү, эш урынында ялган документлар ясау һ.б).
4. Хокук бозуга этәргән ысул (сатып алу, куркыту, вәгъдә итү, алдау, көчләү һ.б).
5. Хокук бозуга этәргән вакыт һәм көн.
6. Хокук бозуга этәргән урын.
7. Хокук бозуга этәргән шартлар (телефоннан сөйләшү, шәхсән очрашу, почта аша җибәрү һ.б.).
8. Хәбәрнамә тутырылган дата.
9. Хәбәрнамәне юллаган дәүләт гражданлык хезмәткәренең имзасы.